Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«16» июнь 2023 Менделеевск ш. № 368

2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («Юл картасы") үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019-2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2019 елның 1 августындагы 306 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елың 26 ноябрендәге АП — 12-397 номерлы беркетмәсе һәм Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерү буенча Милли планны гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча киңәшмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабредәге 835 номерлы “2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы турында” карары белән расланган "2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасы") түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») түбәндәге редакциядә «ритуаль хезмәтләр базары» бүлеге белән тулыландырырга:

| № п/п | Биремне үтәү өчен чараның исеме | Җаваплы башкаручылар һәм төп катнашучылар | Проектны гамәлгә ашыру вакыты | Максатчан индикаторлар | Күрсәткеч индикаторын исәпләү методикасы | ИСКӘРМӘ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Ритуаль хезмәтләр базары | | | | | | |
| 1 | Зиратларны һәм аларда | Менделеевск | 2023-2025 | Реестрга | Абсолют | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күмелгән урыннарны инвентаризацияләүне оештыру, әлеге реестрларны Татарстан Республикасы дәүләт системасы «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре Порталы»нда урнаштырып, зиратлар һәм күмелгән урыннар реестрын булдыру һәм алып бару | муниципаль районы башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары | еллар | кертелгән зиратлар саны: 2023 елда -7; 2024 елда -14; 2025 елда -14. | күрсәткеч. Хисаплау методикасы кирәк түгел | Бар булган зиратларның гомуми санына карата: 2023 ел - 20% 2024 ел -50% 2025 ел - 100% |

1.2. 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планына кушымтаны түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт белән тулыландырырга::

| № п/п | Чараның исеме | Төп вакыйга/нәтиҗә | вакыты | башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 5 | Зиратларны һәм аларда күмелгән урыннарны инвентаризацияләүне оештыру, әлеге реестрларны «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре Порталы»Татарстан Республикасы дәүләт системасында урнаштырып, зиратлар һәм күмелгән урыннар реестрын булдыру һәм алып бару | «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы» Татарстан Республикасы Дәүләт Мәгълүмат Системасында зиратлар һәм аларда җирләү урыннары реестрлары булдырылган һәм урнаштырылган, аларда булган зиратлар һәм аларда җирләү урыннары турында мәгълүматлар кертелгән. | 2025 елның 31 декабре | Менделеевск муниципаль берәмлеге |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарыэлы социаль икътисадый үсеш территориясе һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

килештерелгән:
Башкарма комитет җитәкчесенең

икътисад, алгарышлы социаль икътисадый
үсеш территориясе һәм эшкуарлыкны
үстерү буенча урынбасары Л.Р. Әхмәтов

Менделеевск муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесенең
шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальников

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царёва